КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 28 март г.Казань № 231

Татарстан Республикасы бюджеты, Татарстан Республикасының Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты акчасы исәбеннән инвестицияләрне нигезләүне әзерләүгә һәм аның технологик һәм бәя аудитын үткәрүгә субсидияләр бирү турындагы яки бюджет инвестицияләрен гамәлгә ашыру хакындагы карарларны кабул итү кагыйдәләрен раслау хакында

Татарстан Республикасы Бюджет кодексының $20^1$ статьясындагы $3^1$ пункт һәм $20^{1-2}$ статьясындагы $3^1$ пункт нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән Татарстан Республикасы бюджеты, Татарстан Республикасының Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты акчасы исәбеннән инвестицияләрне нигезләүне әзерләүгә һәм аның технологик һәм бәя аудитын үткәрүгә субсидияләр бирү турындагы яки бюджет инвестицияләрен гамәлгә ашыру хакындагы карарларны кабул итү кагыйдәләрен расларга.

2. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасының Икътисад министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2019 ел, 28 март, 231 нче
карары белән расланды

Татарстан Республикасы бюджеты, Татарстан Республикасының
Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты акчасы исәбеннән
инвестицияләрне нигезләүне әзерләүгә һәм аның технологик һәм
бәя аудитын үткәрүгә субсидияләр бирү турындагы яки бюджет инвестицияләрен
гамәлгә ашыру хакындагы карарларны кабул итү
кагыйдәләре

1. Бу кагыйдәләр түбәндәгеләрне кабул итү тәртибен билгели:

а) Татарстан Республикасы дәүләт милкендә булган (булачак) капиталь төзелеш объектларына карата (алга таба – капиталь төзелеш объектлары) инвестицияләрне нигезләүне әзерләү һәм аның технологик һәм бәя аудитын үткәрү өчен Татарстан Республикасының дәүләт бюджет учреждениеләренә һәм Татарстан Республикасының дәүләт автоном учреждениеләренә (алга таба – учреждениеләр), шулай ук Татарстан Республикасының дәүләт унитар, шул исәптән казна предприятиеләренә (алга таба – предприятиеләр) Татарстан Республикасы бюджетыннан, Татарстан Республикасының Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджетыннан субсидияләр (алга таба – субсидияләр) бирү турындагы карарларны, әгәр дә мондый нигезләүне әзерләү Россия Федерациясе законнары нигезендә мәҗбүри булса;

б) капиталь төзелеш объектларына карата инвестицияләрне нигезләүне әзерләү һәм аның технологик һәм бәя аудитын үткәрү өчен учреждениеләргә һәм предприятиеләргә Татарстан Республикасы бюджеты, Татарстан Республикасының Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты акчасы исәбеннән бюджет инвестицияләрен (алга таба – бюджет инвестицияләре) гамәлгә ашыру турындагы карарларны, әгәр дә мондый нигезләүне әзерләү Россия Федерациясе законнары нигезендә мәҗбүри булса.

2. Карар проектын әзерләү инициативасы белән түбәндәгеләр чыгарга мөмкин:

субсидияләр бирү яки бюджет инвестицияләрен гамәлгә ашыру планлаштырыла торган Татарстан Республикасы дәүләт программасы (алга таба – Татарстан Республикасы дәүләт программасы) чараларын тормышка ашыру өчен җаваплы Татарстан Республикасы бюджеты акчасы белән баш эш итүче, әгәр дә капиталь төзелеш объекты Татарстан Республикасы дәүләт программасына кертелмәгән булса – тиешле алып бару өлкәсендә вәкаләтләр билгеләнгән тәртиптә бирелгән һәм күздә тотыла торган Татарстан Республикасы бюджеты акчасы белән баш эш итүче (алга таба – баш эш итүче);

Татарстан Республикасының Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды (алга таба – баш эш итүче).

3. Баш эш итүче карар проектын әзерли һәм, баш эш итүче бер үк вакытта бюджетны планлаштыру субъекты булып тормаган очракта да, бу проект кем карамагында булуына карап, бюджетны планлаштыру субъекты белән килештерә.

4. Баш эш итүче бер үк вакытта аның җаваплы үтәүчесе булмаган очракта, баш эш итүче карар проектын Татарстан Республикасы дәүләт программасының җаваплы үтәүчесе белән килештерә.

5. Карар проекты Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты боерыгы проекты рәвешендә әзерләнә.

Карар проектына Татарстан Республикасы дәүләт программасының бер чарасына яки баш эш итүче эшчәнлегенең бер өлкәсенә караган бер учреждение яки предприятиенең берничә капиталь төзелеш объекты кертелергә мөмкин.

6. Карар проекты һәр капиталь төзелеш объектына карата түбәндәге мәгълүматны үз эченә ала:

а) капиталь төзелеш объекты исеме;

б) инвестицияләү юнәлеше (төзү, реконструкцияләү (шул исәптән реставрацияләү элементлары белән), техник яңадан җиһазландыру);

в) баш эш итүченең исеме;

г) дәүләт заказчысының (заказчының) исеме);

д) эксплуатацияләүгә тапшырыла торган капиталь төзелеш объектының егәрлеге (егәрлеге арту);

е) инвестицияләрне нигезләүне әзерләү һәм аның технологик һәм бәя аудитын үткәрү вакыты;

ж) субсидияләрнең гомуми (иң чик) күләме (бюджет инвестицияләре күләме) һәм аның еллар буенча бүленеше (инвестиция проектын тормышка ашыруның тиешле еллары буенча бәяләрдә).

7. Чираттагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты проектын төзегәндә баш эш итүче бюджетны планлаштыру субъекты һәм Татарстан Республикасы дәүләт программасының җаваплы үтәүчесе (әгәр дә инвестиция проектын тормышка ашыру Татарстан Республикасы дәүләт программасы чаралары кысаларында планлаштырылган булса) белән килештерелгән карар проектын аңлатма язуы һәм финанс-икътисадый нигезләү белән бергә, чираттагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджетының төп тасвирнамәләрен карап тикшерүнең, чираттагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы дәүләт программалары һәм эшчәнлекнең программада каралмаган юнәлешләре буенча база бюджет ассигнованиеләрен исәпләп чыгару һәм чираттагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджетының өстәмә бюджет ассигнованиеләренең гомуми күләмен бәяләү методикасын раслауның билгеләнгән тәртиптә билгеләнгән көненә кадәр 2 айдан да соңга калмыйча, Татарстан Республикасының Икътисад министрлыгына һәм Татарстан Республикасының Финанс министрлыгына килештерүгә җибәрә.

8. Баш эш итүче карар проекты белән бер үк вакытта баш эш итүченең җитәкчесе (яки аның вәкаләтле заты) кул куйган һәм мөһер белән расланган (булган очракта) түбәндәге документларны Татарстан Республикасының Икътисад министрлыгына һәм Татарстан Республикасының Финанс министрлыгына кертә:

а) капиталь төзелеш объектының кыскача тасвирнамәсен;

б) Татарстан Республикасы бюджетыннан акча бирмичә, инвестицияләрне нигезләүне әзерләү һәм аның технологик һәм бәя аудитын үткәрү мөмкинлеге булмауга нигезләүне.

9. Татарстан Республикасының Икътисад министрлыгы һәм Татарстан Республикасының Финанс министрлыгы карар проектын ул кергән көннән 15 эш көне эчендә карап тикшерә.

10. Карар проектын Татарстан Республикасының Икътисад министрлыгы белән килештерү түбәндәге критерийларны исәпкә алып башкарыла:

а) аны төзү (реконструкцияләү) нәтиҗәләренең сан күрсәткечен (күрсәткечләрен) билгеләп, капиталь төзелеш объектын төзүнең төгәл формалаштырылган максаты булу;

б) капиталь төзелеш объектын төзү максатлары илкүләм (республика) проектларда (әгәр дә капиталь төзелеш объектын төзү илкүләм (республика) проекты кысаларында планлаштырылса) һәм (яки) Татарстан Республикасы дәүләт программаларында (әгәр дә капиталь төзелеш объектын төзү Татарстан Республикасы дәүләт программасы кысаларында планлаштырылса), Татарстан Республикасын социаль-икътисадый үстерү стратегиясендә билгеләнгән максатларга һәм бурычларга, шулай ук тармак доктриналарында, Татарстан Республикасының территориаль планлаштыру концепцияләрендә һәм документларында билгеләнгән өстенлекләргә һәм максатларга туры килү;

в) Татарстан Республикасы Президенты йөкләмәләре һәм күрсәтмәләре, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты йөкләмәләре булу;

г) федераль максатчан программалар, ведомство максатчан программалар һәм республика программалары кысаларында тормышка ашырыла торган чаралар белән үзара бәйләнештә капиталь төзелеш объектын төзегәндә билгеле бер проблеманы тормышка ашыруга комплекслы якын килү;

д) капиталь төзелеш объектын төзүнең Татарстан Республикасы һәм муниципаль берәмлекләр территорияләренең комплекслы үсешенә йогынтысы;

е) капиталь төзелеш объектын төзү нәтиҗәсендә җитештерелә торган продукциягә (эшләргә һәм хезмәт күрсәтүләргә) ихтыяҗны нигезләү.

11. Бу Кагыйдәләрнең 7 нче һәм 9 нчы пунктлары нигезендә кызыксынучы республика башкарма хакимият органнары белән карар проектын килештергәннән соң һәм чираттагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджетының төп тасвирнамәләрен карап тикшергәннән соң, чираттагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы дәүләт программалары һәм программада каралмаган эшчәнлек юнәлешләре буенча база бюджет ассигнованиеләрен исәпләп чыгару һәм чираттагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджетының өстәмә бюджет ассигнованиеләренең гомуми күләмен бәяләү методикасын хуплаганнан соң, баш эш итүче тарафыннан, әгәр дә баш эш итүче бер үк вакытта бюджетны планлаштыру субъекты булып тормаса, бюджетны планлаштыру субъекты тарафыннан карар проекты Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына билгеләнгән тәртиптә кертелә.

12. Карарга үзгәрешләр кертү аны кабул итү өчен бу Кагыйдәләр белән билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла